Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге Советы

**КАРАР №XV-1**

Олы Елга ав 2016 елның 20 июне

Олы Елга авыл җирлеге Советының “Олы Елга авыл җирлеге территориясендә җәмәгать тәртибен көчәйтү буенча өстәмә чаралар турында " 2007 ел, 26 март, 7 нче карарын үз көчен югалткан дип тану хакында

Муниципаль хокукый актны законнарга туры китерү максатыннан, «җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» 2014 елның 2 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Олы Елга авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 33 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының «Олы Елга авыл җирлеге территориясендә җәмәгать тәртибен көчәйтү буенча өстәмә чаралар турында” 2007 ел, 26 март, 7 нче карарын үз көчен югалткан дип санарга.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында: Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25 йорт; Казаклар авылы, Үзәк урам, 9 йорт; Сорочьи Горы авылы, Үзәк урам,16а йорт; Кама поселогы, Курортная-2 урамы, 23 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге Башлыгы Ф.Ә.Садриев